# *Кәлимуллина Мәдинә Әхмәдулла кызы*



*Мин, Кәлимуллина Мәдинә Әхмәдулла кызы, 1941нче елны туганмын. Сугыш башланганын да, сугышның беткәнен дә белмим, яшь бала булганмын ул вакытта. Әтиле балаларга, кешенең аягындагы носкиларына, өстенә кигән күлмәкләренә карап, кызыгып, әрнеп үстем. Әнигә кайтып әйтә идем дә, әни: “Булыр, кызым, булыр”,- дип, сабан туена 50 тиенлек ситсадан күлмәк тегә иде.*

*Сугыш вакытында нәрсә ашаганнарны белмим инде, әни сөйләгәннән генә хәтерлим. Печән чапканга бер сынык ипи бирәләр иде дип әйтә торган иде әни, бәрәңге яфраклары, кычытканнар, яшь бәрәңгеләрне җыеп ашый торган булганнар.*

*Олы Битаман мәктәбендә җиде класс белем алдым, бик яхшы укыдым. Без укыган вакытта мәктәпләр салкын, лампа белән утыра идек. Электр утлары юк, утын ягалар иде.*

*Сугыш бетте, дигән вакытта әтинең хәбәрсез югалган дигән кәгазе килгән. Бөтен кеше куанып, сугыштан кайтучыларны каршы алганда, безнең әниләр елап: “Безнекеләрне күрмәдегезме? Кая үлгән ?” – диеп сорашып йөргәннәр. Мин ул вакытта яшь бала инде.*

*Сугыштан соңгы елларда күкәрин җыя торган идек, әниләр чана белән утын алып кайта торганнар иде. Без аларны каршы ала идек. Җәй көне үлән җыя идек. Кәҗә, тавыклар асрадык. Күкәрин күмәчләре пешереп ашадык. Кузгалаклар, чәчәкләр, юалар белән тукландык.*

*Хәзерге буынга мин шуны теләр идем: саулык - сәламәтлек, эшләрендә уңышлар. Ходай тәгалә юл хәвефләре бирмәсен, укыган балаларның башларына зиһен бирсен. Өйләнгәннәре тигез гомер итсеннәр, эшләсеннәр. Дөньялар тыныч булсын. Сугыш күрмәсеннәр. Без кичергән борчуларны, авырлыкларны балаларыбыз кичермәсен иде.*